ГЛАВА
МАЛЬБАГУШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЗНАКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ул. Нефтяников, д30, с.Мальбагуш,
Азнакаевский муниципальный район 423330

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ МӘЛБАГЫШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ БАШЛЫГЫ

Нефтьчеләр ур., 30 нче йорт, Мәлбагыш авылы,
Азнакай муниципаль районы, 423330

Тел./факс(885592)3-77-90,3-77-91; E-mail:Malb.Azn@tatar.ru,

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«02» ноябрь 2020 ел № 3

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлегенең Мәлбагыш торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Уставы нигезендә, **карар итәм:**

1.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Мәлбагыш авылында Җәлил урамы 1 нче йорттан 58 а йортка, Нефтьчеләр урамы 1 нче йортан 62 нче йортка кадәр, Кооператив урамы 1нче йорттан 10 нчы йортка кадәр теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2020 елның 12 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Мәлбагыш авылында Колхозчылар урамы 1 нче йорттан 16 нчы йортка, Комсомол урамы 1нче йорттан 57 нче йортка кадәр, Мәллә урамы 1 нче йорттан 6 нчы йортка кадәр, Нариман урамы 1нче йорттан 63 нче йортка кадәр теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2020 елның 12 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын билгеләргә.

3.Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Мәлбагыш торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы – Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Башкарма комитеты;
- гражданнар җыенының беренче этабын уздыру вакыты – 12 ноябрь 2020 ел 10.00 сәг.тән 11.00 сәг.кадәр;
- гражданнар җыенының икенче этабын уздыру вакыты – 12 ноябрь 2020 ел 13.00 сәг.тән 14.00 сәг.кадәр;
- гражданнар җыенының беренче һәм икенче этабын уздыру урыны – Мәлбагыш авылы, Җәлил ур. , 4 нче йорт, Мәлбагыш авыл Мәдәният йорты залы;

4. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2020 елның 3 ноябреннән дә соңга калмыйча гражданнарга Мәлбагыш авылы, Нефтьчеләр урамы, 30 нчы йорт адресы буенча урнашкан, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Башкарма комитетында һәм Мәлбагыш авылы, Җәлил урамы, 4 нче йорт адресы буенча урнашкан (авыл мәдәният йорты) мәгълүмат стендында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын бирергә;

- Мәлбагыш торак пунктында сайлау хокукына ия булган яшәүчеләр исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;

- Мәлбагыш торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнарның җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2021 елда 1 төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, Мәлбагыш авыл җирлеге Мәлбагыш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 400 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Мәлбагыш авылының җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту: Мәлбагыш авылы Кооператив урамында һәм Колхоз урамында юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Мәлбагыш авылында юлларны кардан чистарту(килешү буенча түләү);

- җәйге чорда Мәлбагыш авылында үлән чабу, территорияне җыештыру буенча хезмәтләр (килешү буенча эшләр өчен түләү, триммер өчен запас частьләр сатып алу, ягулык-майлау материаллары сатып алу);

- Түбән Якый авылында «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Халыкара инвалидлар көне», «Яңа ел», «Җиңү көне» бәйрәмнәрен оештыру һәм үткәрү (бүләк, сувенир продукция сатып алу);

- Мәлбагыш авылында торак пункт исеме белән стелла әзерләү һәм урнаштыру;

- Мәлбагыш авылында спорт чараларын оештыру һәм үткәрү (бүләк һәм сувенир продукция сатып алу);

- Мәлбагыш авыл җирлегендә урамнарны яктырту һәм урамнарны яктырту буенча хезмәт күрсәтү ( лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җиһазлар сатып алу һәм алыштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү)

« РИЗА» «КАРШЫ»

6. Әлеге карарны Мәлбагыш авылы, Нефтьчеләр урамы, 30 йорт адресы буенча урнашкан, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Башкарма комитетында һәм Мәлбагыш авылы, Җәлил урамы, 4 нче йорт адресы буенча урнашкан (авыл Мәдәният йорты) адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендында Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. урнаштырырга

7. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Башлык: А.Й.Әхмәтшин